-

**ГЛАВА ЛЕНИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. 40 лет Победы д. 32,
с. Ленино, 423181

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЛЕНИНО АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ**
Җиңүнең 40 еллыгы урамы, 32,
Ленино авылы, 423181

тел.: (8-4348) 3-44-16, факс: (8-4348) 3-44-10; Lenin.nsm@tatar.ru_

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

2022 елның 06 октябре №1

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Ленино авыл җирлегенең Горшково авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләп кую турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Ленин авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставының 81 статьясы, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Ленин авыл җирлеге башлыгы

Карар кабул итте:

1. 2022 елның 17 октябренә 13.00 сәгатьтә, Горшково авыл мәдәният йортында (Кыр ур., 54) Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Ленино авыл җирлегенең Горшково авылында яшәүчеләр белән үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.
2. Гражданнар җыенын үткәрү һәм оештыру Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Ленин авыл җирлеге башлыгы тарафыннан тәэмин ителә.
3. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«2023 елда Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Ленино авыл җирлегенең Горшково авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизацияләнгән гражданнардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, 1 төркем инвалидлардан кала, һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә алынган акчаларны Горшково авылы территориясендә түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия булган мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрү белән килешәсезме
- юлларны кардан чистарту (килешү буенча эшләр өчен түләү);
- җәйге чорда территорияне чабу (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);
- Болын урамында балалар уен мәйданчыгын сатып алу, реконструкцияләү һәм урнаштыру (җиһазлар, материаллар сатып алу һәм шартнамә буенча эшләр өчен түләү).

«ӘЙЕ» «ЮК».».

4. Әлеге карарны гражданнар җыены уздырыла торган көнгә кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» http://pravo.tatarstan.ru, Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында http://novosheshminsk.tatarstan.ru/ бастырып чыгарырга (халыкка игълан итәргә), Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Ленино авыл җирлегенең Горшково авылының Кўларты урамы 35а адресы буенча урнашкан мәгълүмат стендында урнаштырырырга.

5. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә
муниципаль районы Ленино
авыл җирлеге башлыгы

С.Ю.Питеркина